


*Куәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№4 Декабрь 2023 ел*



## Әбием канаты астында

Минем әбием - Хәбибуллина Айсылу Мөбәрәкҗан кызы Куәм урта гомуми белем бирү мәктәбендә укытучы булып эшли. Ул балаларга математика фәнен укыта. Әбием инде күп еллар эшли, хезмәтенең нәтиҗәләре дә бик әйбәт: ел саен диярлек аның ярдәме белән күп кенә балалар район, республика олимпиадаларында җиңүче булып кайталар, математика фәненнән имтиханнарны яхшы билгеләргә тапшыралар. Үзе инде өлкән яшьтә булса да, яраткан эшенә бару аның күңеленә рәхәтлек бирә, чөнки ул хезмәтен, балаларны ярата. Әбием җаны-тәне белән һөнәренә чумган, өйгә кайткач та аерыла алмый ул аннан. Үзе укыткан балаларны гына түгел, минем укуымны да бик кайгырта. Компьютерда “ә дигәнче” миңа өстәмә эшләр чыгарып бирә.

Әбиемнең укытучы булуы минем өчен бигрәк тә файдалы булды әле. Әнием эштән кайтканчы аның белән өй эшләрен хәзерләп куябыз.

Әбиемнең куллары алтын, үзе бик уңган. Яшь вакыттан ук аның тегү осталыгы да бар икән. Шуңа күрә, яңа тегү машинасы бүләк иткәч, куанып туя алмады. Ә әбиемнең гөбәдиясе! Телеңне йотарлык була. Кибетнеке кырыйда торып торсын.

Менә шундый уңган-булган минем әбием. Мин аның белән бик горурланам.

**Хәбибуллин Эмиль, 3 нче сыйныф укучысы.**

**Укытучы !**

Белемле, акыллы.

Укыта, уйлата, сөйләтә.

Дөньяны танып белергә өйрәтә.

**Ул – Галим!**

## Укытучы һәм остазлар елы



Шытым салып нәни йөрәкләргә
Белем дөньясына озатучы,
Һәр уңышка сөенүче-
Бары Сез ул, Укытучы!

Әйе, кеше нинди генә юлдан китмәсен, кайсы гына һөнәрне сайламасын, аның үткәне мәктәп елларына барып тоташа. Мәктәп сукмакларында ныклы белем нигезләре алган кеше тормыш юлларында югалмый.

2023 нче ел Педагог һәм остаз елы булып тарихка кереп калачак. Бу ел безнең гаиләгә аеруча да кагылды, чөнки без укытучылар династиясеннән. Олы хөрмәткә лаеклы Дәү әниебез бик күп еллар мәктәптә математика фәнен укыткан остаз. Дәү эти белән Дәү әнинең балалары, кияү, киленнәре, оныклары укытучы һөнәрен сайлаган кешеләр.

Дәү әниебез укыткан укучылар инде үзләре дә бик күптәннән әти-әни, әби –бабай булсалар да , “Безне Назирә апай укыткан иде, бик гади , аңлаешлы аңлата белде”, –дип искә алалар. Дәү әни әле дә гыйлем бирүдән туктамый, аннан әледән - әле киңәшләр сорыйлар, чишә алмаган мисал – мәсьәләләрне җайлы гына юллар белән чишәргә булыша.

Дәү әниебезгә Аллаһы Тәгалә озын гомер бирсен, саулык сәламәтлек өстәсен. Дәү эти белән икесе тигез тормышта безнең янәшәдә әле тагы бик күп еллар яшәсеннәр. Ә без үз чиратыбызда аларны хөрмәтләрбез, яратырбыз , зурларбыз.

Педагог һәм остаз елы узып баруга карамастан укытучыларга булган ихтирам, игътибар кимемәсен иде, укучыларның яратуы сүрелмәсен!

**Гатауллин Ринат, Ришат 3 нче сыйныф укучылары.**

**Укытучы!**

Ягымлы, изге (күңелле).

Тәрбияли, киңәш бирә, ярата.

Иң дөрес, иң туры юлны сайларга өйрәтә.

**Ул – Фәрештә!**

**Галимҗанова Әдилә, 7 нче сыйныф укучысы**

## Ихтирамга лаек сез



Тәрбия сәгатьләрендә ветеран укытучылар турында күп истәлекләр карадык, октябрь аенда күргәзмә дә оештырылды. Зарипова Роза Закиевна, Шигапова Зәлфирә апа, Зарипов Булат абый, Батршина Сания Фаритовна турында язылган материаллар, фотолар тупланды. Мәктәп газетасына мәкаләләр дә яздык. Кызыклы рәсем күргәзмәсе дә карадык. Бу рәсемнәрне ветеран укытучы Фаизов Фәргать абый эшләгән. Ул Куәм урта мәктәбендә өч дистә елдан артык укыткан, укучыларга белем биргән. Биология, география, рәсем дәресләрен укыткан. Мәктәптә 1998 нче елда авылдашыбыз Самат Шакир музеена нигез салына һәм күп еллар дәвамында Фәргать абый күп мәгълүмат туплый, шагыйрьнең гаиләсе белән аралашып яши, музейның җитәкчесе була. Үзе укыткан чордагы укучылар һәм укытучылар турында да күп мәгълүмат туплаган, аңарга күп фотолар һәм язмалар бар. Аеруча бер дәфтәргә исемлеккә игътибар иттек. Бу исемлектә укытучы үзе эшләгән чордагы чыгарылыш класс укучыларын язып барган. Бу исемлек үзе бер тарих. Монда без белгән күп кешеләр, безнең әти әниләр дә язып куелган. Мәктәп еллары тиз уза, ди класс җитәкчебез Ләйсән апа. Бу елларны файдалы , кызыклы уздыру бездән дә тора. Без быел чыгарылыш класс укучылары, алда имтиханнар бар. Безне укыткан укытучыларга рәхмәтләребезне җиткерәбез. Эшләрендә уңышлар , сәламәтлек телибез.

**Ганиева Дилә 9 нчы сыйныф укучысы**



## Дөньяда һөнәрләр күп.

Аларның төрле булуы, кызыклы һәм файдалы, җаваплы һәм таләпле икәнен һәркем белә. Һәр кеше үзенә туры килгәнен сайлап ала. Сайлаган һөнәрен сиңа җимеш китерсен өчен, кеше белемгә таянырга тиеш. Һөнәренә тугры булып, тормышта дөрес итеп яшәргә бурычлы. Шундый һөнәрләрнең берсе булып - укытучы һөнәре тора.

Безнең гаиләдә “Укытучы” лар бик күп. Минем әбием, әнием Гөлүсә, апаем Гөлназ, бертуган апам Зөхрә дә шул һөнәр ияләре. Алар үз эшләрен яратып, җаваплы карап башкаралар. Хәтта, апаем Гөлназ үзе белем биреп чыгарган укучыларының балаларын да укыта.Тарих тәгәрмәченә күз салсаң, ул Куәм урта мәктәбендә 34 ел эшли. Апаем үз һөнәрен ярата, укучыларына да төпле белем бирә.Ул минем беренче укытучым иде. Безне тырыш, белемле, мәрхәмәтле булырга өйрәтте.

**Газизов Сәйдәш, 8 нче сыйныф укучысы**

## Мин аның белән горурланам



Минем әнием - Ганиева Люция Фәесхан кызы Куәм урта гомуми белем мәктәбендә башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли. Ул 1990 нчы елда безнең мәктәпкә укытучы булып эшкә килә. Менә инде 25 елдан артык минем әнием- укытучы.Ул белем бирүгә бик җаваплы карый, һәркөнне укучылары турында куанып искә ала.

Мин анын белән горурланам. Укытучы эше ул- бик җаваплы һөнәр!

**Ганиева Зөхрә, 8 нче сыйныф укучысы**

## Үземә охшаган әбием



Минем Зәлфирә әбием бар. Әбием, мин укыган мәктәптә бик күп еллар пионервожатый булып эшләгән, җыр дәресләре укыткан. Аның укыткан укучылары да гел хәлен белеп, хөрмәт итеп торалар.

Дусым авылында балалар бакчасы ачылгач, Зәлфирә әбием бакчада эшләде. Бакчадагы балалар да әбине бик яратып, “әби” дип йөриләр иде. Мин дә, апаларым да, әби бакчада эшләгәндә аның тәрбиясендә булдык. Көн дә мәктәптән кайтканда, башта аның янына кереп, тәмле чәен эчеп, хәлен белеп өйгә кайтып китәм. Ул мине көтеп ала. “Сөйләшүләрең миңа ошаган, бигрәк яратам инде”, дип сөя. Мин дә әбиемне бик яратам.

**Шигапов Риназ, 3 нче сыйныф укучысы.**



Килегез, кил кошкайлар,

Сез бит безнең дускайлар.

Мәктәп янына килегез ,

Җимлекләрне күрегез.

**Ахметшин Илмир 1нче сыйныф укучысы**

## Изге һөнәр иясе



Укытучы - ул изге һөнәр. Балаларыбызның, халкыбызның киләчәге – укытучы кулында, аның алтын йөрәгендә. Шуңа күрә кеше тормышында укытучының роле һәм урыны бәяләп бетергесез. Укытучы исеменә лаек булу ул – зур бер батырлык дип әйтер идем мин. Ни өчен дигәндә: бары тик көчле рухлы, сабыр кеше генә бу эшкә күңелен биреп, тиешле дәрәҗәдә укыту сәләтенә ия була аладыр. Ганиева Ләйсән Фәргать кызы белән менә инде бик күп еллар иңне – иңгә куеп хезмәт итәбез. Ул бик сабыр, коллега буларак бик ярдәмчел, укытучы буларак бик ягымлы. Аның мөлаем итеп елмаюы гына да күңелне канатландыра. Аның укучылары белән мәш килеп йөрүе, алар өчен борчылуы, ярдәм итүе – аның бу һөнәрне дөрес сайлавына ачык мисал булып тора.

Коллегам буларак, мин аңа сокланам. Ул бик белемле, күп эзләнә, барысыннан да хәбәрдар. Ай саен алдыра торган “ Мәгариф” журналын ачуга, гел аның фәнни мәкаләләренә юлыгам. Экология фәне буенча “Мәгариф” журналы оештырган, елга берничә тапкыр уза торган “Яшел бишек” бәйгесендә катнашып, гел беренче урыннарга гына ия булган хезмәттәшем өчен чын күңелемнән шатланам.

Укытучы һөнәре – чын мәгънәсендә һөнәрләр һөнәре. Мөгаллим ул – гомере буе укый, өйрәнә, үзенең һәм укучыларының уңышларына чын күңелдән сөенә белүче, көчле ихтыярлы, сабыр кеше. Нәкъ шул сүзләрне мин Ләйсән Фәргать кызы турында да әйтер идем. Ул бик иҗади шәхес. Аның бу иҗадилыгы әтисе – Фәизов Фәргать Гарифҗан улыннан күчкәндер. Фәргать абыйның иҗат лабораториясе чиксез бай. Элеге вакытта да, ул “аяклы тарих”. Мәктәптә нинди генә чара узса да, аның картиналары, җыйган материаллары безнең өчен бик зур ярдәм.

Хезмәттәшем үзе дә, аның укучылары да төрле бәйгеләрдә катнашалар, призлы урыннар яулыйлар. Укучыларга белем һәм тәрбия бирүдә Ләйсән Фәргать кызының өлеше зур. Аны укытып, тәрбияләп чыгарган укучылары да бик хөрмәт итә, аннан үрнәк ала.

**Сөнгатова Гөлнара Зөлкарь кызы,**
**тарих укытучысы**

## 2023 нче ел – Укытучы һәм остаз елы

Бу ел тәмамлану алдында тора. Ул үзенең бик күп эшләнгән эшләре белән тарихка кереп калыр. Укытучы һәм остаз елы - укытучыга хөрмәт, аларның югары статусын тану һәм аларның башкарган эшенең мөһимлеге турында сөйли. Президент биргән күп йөкләмәләр укытучы һөнәренең абруен күтәрүгә, аларга социаль ярдәм күрсәтүгә, һөнәри үсешкә карашны үзгәртүгә юнәлтелде. Укытучыларыбызны һәм остазларыбызны үтеп баручы елның уңышлары белән чын күңелдән тәбриклибез. Сәламәтлек, бәхет һәм шатлык телибез. Килер көннәре тагын да аяз, уңышлары чиксез булсын. Аяз күк йөзендәге кояшлары гел яктыртып, укучыларына юл күрсәтсен. Киләчәктә уңышлар Сезгә, хөрмәтле укытучыларыбыз!

## Кыш



Кар ява, матур булып,

Бар җир кабарып тора.

Һәр бөртеге

ялтыравыклы.

Җем- җем итеп

Күзларне камаштыра.

Биек, биек таулар булыр

Кичкә хәтле уйнарбыз шуып ,

Әни керткәчне куып.

**Садриева Ралия 1 нче сыйныф укучысы**



## Яраткан сыйныф җитәкчем

Һәрбер баланың да тормышында ике зур, мөһим йорты була: туган йорты һәм мәктәп. Бары тик шушы йортларда аңа яшәү, тормыш, белем, акыл, тәрбия сүзләренең мәгънәсен аңлаталар, зур тормышка әзерлиләр. Әзерләүчеләре кем дисезме? Әти-әниләр һәм укытучылар! Аларның хезмәте-тормышта үзләренең көчен, сәләтен балаларга багышлауны таләп итә. Шуңа күрә укытучы-баланың "икенче әнисе" дип әйтәбез. Мин үземнең укытучым Гөлнара Зөлкарь кызы турында язасым килә.

Без сыйныфта алты кыз, биш малай. Балаларның уенданиләр икәнен беләсез инде: хәрәкәтле уеннар, кызыксыну, төрле кыланулар. Ә укытучыбыз-сабыр, итагатьле, безнең йөрәкләрдә һәрбер өлкәне танып белүгә кызыксыну уятучы, һәрберебезне үз балаларыннан да якын күрүче, авыр чакта ярдәмчебез, киңәшчебез! Безне бердәм, дус, тату сыйныф итеп туплавы аңа бер дә җиңел булмагандыр. Гөлнара апаның сабырлыгына сокланырлык! Укытучыбыз, сыйныф җитәкчебез белән без горурланабыз. Гөлнара апаның сыйныфында укуыбыз белән без бик бәхетле, без аны бик яратабыз!

**Шакирова Камилә, 6 нчы сыйныф укучысы**